ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
19.03.2026

**К А Р А Р**
№ 267

**«2026-2028 елларга Биектау муниципаль районында террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Терроризмга каршы көрәш турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы көрәш турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы, «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» 2022 елның 9 ноябрендәге 809 номерлы һәм «Россия Федерациясе Тышкы сәясәт концепциясен раслау турында» 2023 елның 31 мартындагы 229 номерлы, «Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында» 2024 елның 28 декабрендәге 1124 номерлы Указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын саклау дәрәҗәсен арттыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «2026-2028 елларга Биектау муниципаль районында террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын расларга.
2. Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджетын формалаштырганда

мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм Биектау районы бюджетыннан әлеге максатларга юнәлдерелә торган акчалар чикләрендә муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга акча кертергә.

3. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru / халыкка җиткерергә һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

*1 нче кушымта*

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.03.2026 № 267
номерлы карары белән расланды

# «2026-2028 ЕЛЛАРГА БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ТЕРРОРЧЫЛЫК ҺӘМ ЭКСТРЕМИСТЛЫКНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ» ПРОГРАММАСЫ

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2026-2028 елларга Биектау муниципаль районында террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау» программасы (алга таба Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Терроризмга каршы көрәш турында» 2006 елның 06 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы көрәш турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы, «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» 2022 елның 9 ноябрендәге 809 номерлы һәм «Россия Федерациясе Тышкы сәясәт концепциясен раслау турында» 2023 елның 31 мартындагы 229 номерлы, «Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында» 2024 елның 28 декабрендәге 1124 номерлы Указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән |
| Программаның заказчысы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны | Биектау муниципаль районында Терроризмга каршы көрәш |

<table>
<tr><td>эшләүче</td><td>комиссиясе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td>Татарстан республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышы һәм тынычлыгы, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен экстремизм һәм террорчылыкка каршы тору, районда аларның чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү нигезендә күтәрү.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмый калу;<br>Террорчылык һәм экстремистик идеология күренешләренә халыкта түзеп тормау атмосферасын булдыруга юнәлдерелгән иҗтимагый фикерне формалаштыру;<br>Күпмилләтле Россия җәмгыяте кыйммәтләре, мәдәни үзаң, кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау принциплары нигезендә башка милләт һәм дини конфессияләр кешеләренә карата халыкның толерант үз-үзен тотышына эчке ихтыяҗын формалаштыру.<br>Биектау муниципаль районы халкына террорчылык һәм экстремизмга каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерү;<br>Балалар һәм яшьләр арасында экстремистик характердагы гамәлләрне кылуга ярдәм итә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән тәрбия эшен оештыру;<br>Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә, җәмәгатьчелек, дәүләтнеке булмаган структуралар, ММЧ, галимнәр, руханилар, хокук саклау органнары катнашында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы юнәлдерелгән мәгълүмати-пропаганда эшчәнлеген көчәйтү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2026-2028</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау (күләмнәре һәм чыганаклары)</td><td><table>
<tr><td></td><td colspan="4">Гамәлгә ашыру еллары</td></tr>
<tr><td></td><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td><td>Барысы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет (мең сум)</td><td>25706,0</td><td>23426,9</td><td>23426,9</td><td>72559,8</td></tr>
</table>
Әлеге Программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Татарстан Респбликасы Биектау муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла. Программаны гамәлгә ашыруга тотыла торган акчалар күләме район</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | бюджеты мөмкинлекләреннән, Татарстан Респбликасы Биектау муниципаль территориясендә инфляция процессларыннан һәм икътисадый ситуациядән чыгып төгәллек кертелергә һәм төзәтелергә мөмкин |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә террорчылыкны һәм экстремистлыкны, ксенофобия, милли, раса, социаль - сәяси каршылыкны профилактикалау, этник дискриминациягә каршы көрәшү буенча җирле үзидарә органнарының эш формаларын һәм ысулларын камилләштерү.<br>Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары даирәсендә интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын тарату.<br>Милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү, этносоциаль уңайлылык дәрәҗәсен күтәрү.<br>Террорчылык һәм экстремистик күренешләрнең барлык фактларына түзеп тормаучанлык, шулай ук башка этник һәм конфессиональ бергәлекләр вәкилләренә толерант аң, уңай караш формалаштыру, социаль-сәяси җирлектә террорчылык һәм экстремизм үсүгә юл куймау.<br>Яшьләр арасында милләтара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм культивацияләү.<br>Милләтчелек экстремистик яшьләр төркемнәрен оешуны һәм аларның эшчәнлеген булдырмау.<br>Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә толерантлык, гражданлык теләктәшлеге, башка культураларга хөрмәт идеяләрен, шул исәптән муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары аша тарату һәм пропагандалау өчен бердәм мәгълүмат киңлеген формалаштыру. |

## I. Хәл ителүенә Программа юнәлдерелгән мәсьәләне характерлау

Биектау муниципаль районында иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы тулаем алганда төрле социаль төркемнәр, милләтләр һәм диннәр вәкилләренең тотрыклылык, ярдәмләшү, тыныч конструктив үзара эшчәнлек һәм хезмәттәшлек рухы белән характерлана.

Тышкы куркыныч тудыручы факторлар булып Украина махсус хезмәтләре һәм милләтчелек формированиеләре оештырган диверсион-

террорчылык акцияләре куркынычы, Сирия һәм Гыйрак территориясендә террорчылык оешмалары әгъзаларының эшчәнлеге, Татарстан Республикасында халыкара террорчылык һәм экстремистлык оешмалары әгъзаларының һәм ярдәмчеләренең булуы, шулай ук Интернет челтәре аша яшьләр тирәлегенә тискәре йогынты ясау тора. Махсус хәрби операция зонасында Украина Кораллы формированиеләренең уңышсызлыклары белән бәйле рәвештә янаулар көчәйде, пилотсыз очу аппаратлары һөҗүмнәре саны берничә тапкыр артты.

Террорчылыкка каршы тору өлкәсендәге хәлгә йогынты ясый торган төп эчке куркыныч тудыручы факторлар булып район территориясендә экстремизмга каршы тору линиясе буенча оператив-профилактик исәптә торучы теркәлгән затларның һәм аларның якын туганнарының (хатыннары, ирләре, балалары һәм фикердәшләре) булуы тора. Иҗтимагый-сәяси вәзгыятькә анализ күрсәткәнчә, Биектау районы территориясендә нинди дә булса иҗтимагый-сәяси протест акцияләре (санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән) үткәрелмәгән. Шул ук вакытта хезмәт күрсәтелә торган территориядә «Татар иҗтимагый үзәге» һәм «Азатлык татар яшьләре берлеге» кебек радикаль оппозицион хәрәкәтләрнең аерым вәкилләре яшәвен билгеләп үтәргә кирәк. Элегрәк экстремистлык һәм террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган өчен җаваплылыкка тартылган затлар хокук саклау органнары күзәтчелегендә торалар, шулай ук ведомствоара эш төркеме кысаларында алар һәм аларның гаилә әгъзалары белән эш алып барыла.

Соңгы елларда Татарстан Республикасы хокук саклау органнары тарафыннан экстремистик һәм коралланган террорчылык төркемнәрен ачыклау очраклары ешая. Республиканың берничә дистә кешесе Сирия, Украина территориясендәге террорчылык оешмалары составында хәрби хәрәкәтләрдә катнаша.

Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендәге хәл начараю тенденциясе түбәндәге шартларга бәйле булырга мөмкин:

- Россия Федерациясе территориясендә халыкара террорчылык һәм экстремистлык оешмалары эшчәнлеге активлашуга бәйле рәвештә экстремизм һәм террорчылык актлары барлыкка килү янау һәм куркынычы дәрәҗәсе арту;

- халык арасында мәгълүмати-пропаганда эшенең җитәрлек булмавы; үсеп килүче буынга белем һәм тәрбия бирү, укучыларга гражданлык һәм милләтара татулыкка нигезләнгән гомумгуманитар кыйммәтләр формалаштыруга нәтиҗәле юнәлеш бирү өлкәсендәге проблемалар белән; террорчылыкка, экстремизмга каршы профилактика, кисәтү һәм көрәш өчен җаваплы белгечләрнең җитәрлек дәрәҗәдә компетентлы булмавы. Татарстан территориясендә күп санлы эре халыкара чаралар уздыруга бәйле рәвештә

террорчылыкка каршы һәм экстремистлыкка каршы юнәлдерелгән чаралар кабул итүнең актуальлеге арта.

Аның йогынтысының төп мишене булып, гражданлык тәңгәллеге һәм хокук аңы формалашу күзлегеннән чыгып караганда иң үзгәрүчән һәм тотрыксыз мохит буларак яшүсмерләр һәм яшьләр хезмәт итә. Экстремизм - гомуми куркыныч, һәм аның идеологиясен дәүләт һәм муниципаль институтларның, фәнни һәм мәгариф даирәләренең, бизнес-берләшмәләрнең, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм гражданлык җәмгыяте структураларының уртак координацияләнгән көрәше белән генә җиңәргә мөмкин.

Иң экстремист куркыныч тудыручы төркем булып яшьләр тора, бу социаль - икътисади шулай ук этнодини факторлар аркасында килеп чыга.

Яшь кешеләрнең гомумбелемлелек һәм гомуммәдәнилек дәрәҗәсенең кимүе аеруча сагайта, моннан экстремистлыкка көйләнгән радикаль сәяси һәм дини көчләр файдалана.

Шулай итеп, экстремизм, террорчылык һәм җинаятьчелек иҗтимагый иминлеккә реаль куркыныч тудыра, җирле үзидарә органнарының абруен җимерә һәм иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә тискәре йогынты ясый. Аларның чагылышлары социаль киеренкелек тудыра, җинаятьчел гамәлләрдән турыдан-туры һәм читләтеп зыянны бетерүгә халыкның, оешмаларның һәм предприятиеләрнең чыгымнарына китерә.

Экстремизмга, терроризмга, хокук бозуларга ярдәм итүче сәбәпләрне һәм шартларны кисәтүгә, ачыклауга, бетерүгә юнәлдерелгән чараларга системалы якын килү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында социаль-икътисадый хәлне яхшыртуның иң мөһим шартларының берсе булып тора.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык документ булып тора.

## II. Срокларын, шулай ук көтелгән нәтиҗәләрне күрсәтеп, Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максатлары булып тора:

-Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышы һәм тынычлыгы саклану дәрәҗәсен, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен экстремизмга һәм

терроризмга каршы тору, аларның күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү нигезендә арттыру;

- Биектау муниципаль районы территориясендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

- Биектау муниципаль районы халкын җыелма тәшкил итүче барлык халыклар һәм конфессияләр вәкилләренең цивилизацияле үсеше һәм тормыш эшчәнлеге өчен сәяси-хокукый, социаль-икътисадый, мәдәни-көнкүреш, рухи-әхлакый һәм башка шартлар тудыру һәм аларга ярдәм итү.

Программаның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- социаль-сәяси, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмау;

- күпмилләтле Россия җәмгыяте кыйммәтләре, мәдәни үзаң, кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау принциплары нигезендә халыкның башка милләт һәм дини конфессияләр кешеләренә карата толерант үз-үзен тотышын булдыру;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы халкына террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү;

- хокук саклау органнарына әлеге категориядәге хокук бозуларны һәм җинаятьләрне ачыклауда, шулай ук аларның нәтиҗәләрен бетерүдә ярдәм итү;

- башка милләт һәм дини конфессияләр кешеләренә карата толерант караш пропагандалау;

- балалар һәм яшьләр арасында экстремистик характердагы гамәлләрне кылуга ярдәм итә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән тәрбия эшен оештыру;

- гражданнарның уяулыгын, хокукый хәбәрдарлыгын һәм хокукый культурасын күтәрү.

Терроризм бүген бөтен дөнья җәмәгатьчелеге өчен җитди проблемага әверелде, һәм нәтиҗәле каршы тору системасын булдырганда аңа дәүләтләрнең, махсус хезмәтләрнең һәм хокук саклау органнарының уртак тырышлыгы кирәк. Әлеге гомумдәүләт проблемасын хәл итү өчен бу социаль-сәяси күренешкә каршы Россия Федерациясенең киләчәге өчен дәүләтнең һәм җәмгыятьнең барлык җаваплы көчләрен берләштерергә кирәк. Әлеге Программа, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш, мәдәният учреждениеләрен, массакүләм мәгълүмат чараларын, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләрне колачларга тиеш.

## III. Программаны гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре

Терроризмга каршы көрәш, икътисадый, сәяси, социаль һәм махсус характердагы чаралары булырга тиешле комплекслы якын килүне таләп итә.

Программаны гамәлгә ашыруны түбәндәге юнәлешләрдә алып барырга кирәк:

- режимлы чараларның нәтиҗәлелеген, барыннан да элек миграция агымнарын контрольдә тоту өлкәсендә арттыру;
- террорчылыкка һәм җинаять террорчылыгына каршы көрәшнең үзара бәйләнеше;
- гамәлгә ашырыла торган чараларны координацияләү өчен җаваплылыкның бердәм үзәген билгеләү белән террорчылыкка каршы көрәштә хокук тәртибе һәм махсус хезмәтләр көчләренең үзара хезмәттәшлеге:
- террорчылыкка каршы көрәштә катнашучыларның бердәм мәгълүмат системасын булдыру;
- террорчылыкка каршы көрәштә массакүләм мәгълүмат чаралары, сәяси һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек.

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәге принципларга нигезләнгән:

- дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының, иҗтимагый һәм сәяси оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм халык көчен берләштерү нигезендә террорчылыкка каршы комплекслы көрәш;
- террорчылык янауларына каршы контрчаралар куллану үз вакытында һәм адекват булу;
- милли толерантлыкка нигезләнгән идеологияне үстерү һәм гамәлгә кертү; дәүләт органнарының террорчылык һәм экстремизм күренешләренең барлык рәвешләренә адекват реакциясе;
- террорчылык һәм экстремизм таралуга каршы көрәшкә халыкны җәлеп итү.

Әлеге Программа кысаларында террорчылыкка каршы эшчәнлекнең база нигезләре түбәндәгеләр: гуманлылык; социаль гаделлек; объективлык; халык ярдәменә һәм ышанычына таяну.

## IV. Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Чараларны финанслау җирле бюджет хисабына гамәлгә ашырыла.

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау субъектлары эшчәнлеген координацияләү Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе билгеләгән вәкаләтле орган (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле орган кабул итә торган карарлар (беркетмәләр) тиешле профилактика субъектлары тарафыннан башкарыла. Вәкаләтле орган каршында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауның аерым юнәлешләре буенча яисә бу өлкәдә конкрет

проблеманы хәл итү өчен эш комиссияләре (төркемнәре) төзелергә мөмкин. Профилактика субъектларында штаттан тыш нигездә вәкаләтле орган белән хезмәттәшлек итү, программа чараларын башкаруны координацияләү, кабул ителә торган карарларны аларга кагылышлы өлештә гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган эш төркемнәре төзелергә мөмкин. Вәкаләтле орган эшендә катнашуга аларның ризалыгы белән суд органнары һәм прокуратура вәкилләре чакырылырга мөмкин. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау торышына комплексны анализ ясау, аннары профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча озак сроклы муниципаль комплекслы максатчан программалар проектларын эшләү, аларның үтәлешен, бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылуын контрольдә тоту;
- Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә профилактика эшчәнлеге торышы турында мәгълүмат бирү, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр кертү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү, аларны башкаруга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү мәсьәләләре буенча предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләрен (алга таба - профилактика субъектлары) тыңлауны оештыру;
- террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү буенча профилактика субъектларының эшчәнлеген координацияләү; террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә законнар һәм башка норматив хокукый актлар проектларын әзерләү; халык, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән тыгыз хезмәттәшлекне ныгыту һәм җайга салу.

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәү өчен, аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан максатчан файдалану өчен җаваплылык җирле үзидарә органнары карамагындагы район оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә йөкләнә.

Чараларны үтәү өчен җаваплы район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм җирле үзидарә органнары, билгеләнгән тәртиптә аларның үтәлеше турында вәкаләтле органга мәгълүмат бирәләр. Программаны үтәү барышы Биектау муниципаль районының Террорчылыкка каршы комиссиясе утырышларында карала, аларда Программаны башкаручылар тыңлана. Программа чараларының үз вакытында һәм сыйфатлы үтәлүен контрольдә тотуны вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

## V. Программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеге террористик актлар янаулары дәрәҗәсе кимү нигезендә бәяләнәчәк. Социаль нәтиҗәлелек социологик тикшеренүләр мәгълүматларына нигезләнеп бәяләнәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- район территориясендә террорчылык актларын кылуны минимальләштерү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны социаль профилактикалауның нәтиҗәлелеген күтәрү, предприятиеләр, учреждениеләр, барлык милек формаларындагы оешмалар, шулай ук иҗтимагый оешмаларны террорчылык һәм экстремизмны кисәтү эшчәнлеген оештыруга җәлеп итү;
- террорчылык һәм экстремизмны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин итү;
- Биектау муниципаль районы территориясендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту;
- Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына халык ышанычы дәрәҗәсен күтәрү.

## VI. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ БУЕНЧА ФИНАНСЛАУ

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Төп чараларның исемнәре | Башкару чылар | Төп чаралар ны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар кыйммәте (еллар буенча) | | | | Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары һәм өстәмә керемнәр исәбеннән финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2025 (база) | 2026 | 2027 | 2028 | 2025 (база) | 2026 | 2027 | 2028 |
| * Максат: Биектау муниципаль районы территория сендә яшәүче гражданнар ның тормышы һәм тынычлыгы, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгать ләрен яклау дәрәҗәсен экстремизм һәм террорчыл ыкка каршы тору, аларның чагылышла рын районда профилакти калау һәм кисәтү | 1 бурыч. Террорчыл ык идеоло гиясе йогынтысы на дучар булган, шулай ук аның йогынтысы на эләккән затлар белән профилакт ик эш өчен шартлар тәэмин итү | 1. ПООда һәм кешеләр күп була торган объектларда видеокамералар һәм ашыгыч сөйләм хәбәр итү система лары урнаштыру | БМР БК Мәдәният бүлеге | 2026-2028 | Урнаштырылг ан видео камералар һәм ашыгыч сөйләм хәбәр итү система лары саны | | | | | 353,0 | 353,0 | 353,0 | 353,0 |
| | | 1.1. Мәгариф объектларының һәм кешеләр күпләп була торган объектларның террорчылыкка каршы якланганлыгы кимчелекләрен этаплап бетерү | БМР БК Мәгариф бүлеге<br>АҖ | | | | | | | 580,0 | 2279,1 | - | - |
| | | 1.2. Муниципаль учреждениеләрн | БМР БК Мәгариф | | | | | | | 21123,1 | 21847,5 | 21847,5 | 21847,5 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нигезендә күтәрү | | е хосусый саклау оешмалары тарафыннан саклауны оештыру | бүлеге | | | | | | | | | | |
| | | | БМР БК ЯЭСБ, | | | | | | | - | 1226,4 | 1226,4 | 1226,4 |
| | | 1.2. «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары белән эшләү буенча муниципаль ведомствоара эш төркеменең эшен тәэмин итәргә | БМР БК, ҖҮО башлыклары, БР буенча ЭЭМБ, ФКХ вәкиле | 2026-2028 | Эшче төркемнәрнең утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | * | * | * | * |
| | | 1.2. «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары белән адреслы профилактик чараларда катнашуга коммерциячел булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм иҗтимагый активистларны кызыксындыру чараларын | БМР БК, ҖҮО башлыклары | 2026-2028 | Җәмәгать активистларын җәлеп итеп профилактик эш белән колачланган «махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары өлеше | 70 | 70 | 70 | 70 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | гамәлгә ашырырга | | | | | | | | | | | |
| | | 1.3. «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе кешеләре белән эшләүгә, аларның торышын диагностикалау, психологик һәм психотерапевтик ярдәм күрсәтү өчен җәлеп ителгән вазыйфаи затларны һәм иҗтимагый активистларны әзерләү, квалификацияле белгечләр җәлеп итүне тәэмин итәргә | БМР БК | 2026-2028 | Өйрәтелгән, квалифик ацияле белгечләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |
| | | 1.4. Яшьләр тармагы белгечләре, спорт оешмалары, яшьләр иҗтимагый активистларыны | БМР БК ЯЭСБ, | 2026-2028 | Күрсәтелгән хезмәтләр төрләре белән колачланган «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе | 25 | 25 | 25 | 25 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ң «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затларын социализацияләү характерындагы өзлексез ярдәм чараларын гамәлгә ашыруда актив катнашуын тәэмин итәргә | | | затлары өлеше | | | | | | | | |
| | | 1.5. Функциональ регламент белән беркетелгән мәгариф оешмалары вазыйфаи затларының «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары белән алдан ук адреслы эш алып баруда актив катнашуын тәэмин итәргә | БМР БК Мәгариф бүлеге | 2026-2028 | «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары (яисә аларның балалары) белем ала торган уку сыйныфлары булган төркемле корректлаучы чаралар (тренинг, семинарлар) өлеше | 90 | 90 | 95 | 95 | * | * | * | * |
| | | 1.6. Балигъ булмаганнарның | БМР БК, БМРда ТК | 2026-2028 | | +10% | +10% | +10% | +10% | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык субъектлары белгечләренең «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе гаиләләре белән профилактик чараларны, шул исәптән торгызу медиациясе техникаларын кулланып, гамәлгә ашыруда актив катнашуын тәэмин итәргә | К, балигъ булмаган нарның күзәтүче сезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары | | | | | | | | | | |
| | | 1.7. Адреслы профилактик эштә катнашучы белгечләрнең һөнәри осталыгы буенча тармакара семинарларын уздырырга | БМР БК, БМРда ТКК | 2026-2028 | Семинарлар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |
| | | 1.8. Мәгариф, | БМР БК | 2026-2028 | Күрсәтелгән | +10% | +10% | +10% | +10% | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшьләр, медицина, социаль яклау өлкәсенә социаль педагоглар, психиатрларны җәлеп итү өчен яшьләр арасында һәм мәгариф өлкәсендә профориентация эше үткәрергә, тиешле белем алу һәм белгечлек буенча муниципаль берәмлектә алга таба эшкә урнашу өчен мәгълүмати ярдәм күрсәтергә | МБ, БМР БК ЯЭСБ, СЯБ, «Биектау ҮРХ» ДАССУ | | тармакларда белгечләрне туплау проценты | | | | | | |
| | | 1.9. Террорчылык идеологиясен ныклы кабул итмәүне булдыруга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, гавами чараларда традицион | БМР БК, БР буенча ЭЭМБ, ФКХ, «Татмедиа» ААҖ филиалы | 2026-2028 | Мондый аңлатмалар белән чыгыш ясаган «Махсус игътибар» (хәтәр) категориясе затлары өлеш | 10 | 10 | 10 | 10 | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен булдыруга юнәлдерелгән чыгышларга Махсус игътибар (хәтәр) категориясе затларын җәлеп итү буенча эш алып бару | | | | | | | | | | |
| | | 1.10. Системалы хезмәт һәм уку процессларына җәлеп ителмәгән яшьләрне, шулай ук формаль булмаган яшьләр формированиеләре вәкилләрен, иҗтимагый әһәмиятле социаль проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруга җәлеп итү чараларын оештырырга һәм уздырырга | БМР БК ЯЭСБ | 2026-2028 | Максатчан аудиториянең гомуми санына колачланган яшьләр өлеше | +10% | +10% | +10% | +10% | * | * | * | * |
| | | 1.11. Интернет челтәрендә | БМР БК ЯЭСБ, БМР | 2026-2028 | Мониторинг нәтиҗәләре | 12 | 12 | 12 | 12 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | деструктив бергәлекләрдә муниципаль берәмлек халкының активлыгына мониторинг уздыруны тәэмин итәргә (катнашучыларны матди кызыксындыру) | БК МБ, Форпост МБУ | | буенча мәгълүмати белешмәләр саны | | | | | | | | |
| | | 1.12. Экстремизм билгеләре булу-булмауга муниципаль берәмлектә таратыла торган материалларны даими мониторинглауны оештырырга һәм тикшерүләр уздырырга | БМР БК | 2026-2028 | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |
| | 2 бурыч. Биектау муниципаль районы халкының террорчылыкка каршы аңын | 2.1. Мәгълүмат - пропаганда төркеме эшчәнлеген тәэмин итәргә (катнашучыларны матди кызыксындыру) | БМР БК, ҖҮО башлыклары, ТРда ТОГВ, БРда ЭЭМБ, дини, иҗтимагый, | 2026-2028 | Количество заседаний рабочих групп | 4 | 4 | 4 | 4 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | формалаштыру | | мәгариф һәм фәнни оешмалар | | | | | | | | | | |
| | | 2.2. Террорчылыкка каршы юнәлешле күргәзмә агитация продукциясен (стикерлар, брошюралар, плакатлар) эшләргә, әзерләргә һәм таратырга (урнаштырырга) | БМР БК, ҖҮО башлыклары | 2026-2028 | Җәмәгать игътибары өчен урнаштырылган продукция берәмлекләре саны | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |
| | | 2.4. Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып баруга квалификацияле лектор-пропагандистлар муниципаль активын әзерләүне тәэмин итәргә | БМР БК, ҖҮО башлыклары | 2026-2028 | Муниципаль берәмлектә яшәүчеләрдән укытылган, квалификацияле лекторлар саны | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |
| | | 2.5. Террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлек көненә | БМР БК МБ, БМР БК МәдБ, БМР БК СБ, БМР | 2026-2028 | Чаралар саны | | | | | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | багышланган иҗтимагый - сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары (3 сентябрь) үткәрергә | БК ЯЭСБ, «Татмедиа» ААҖ филиалы | | | | | | | | | | |
| | | 2.6.Экстремизм һәм террорчылыкка каршы көрәш буенча видеороликлар, плакатлар бәйгесе үткәрергә | БМР БК МБ, | 2026-2028 | | | | | | - | 10,0** | 10,0** | 10,0** |
| | | | БМР БК МәдБ, | | | | | | | - | 30,0** | 30,0** | 30,0** |
| | | 2.7. Муниципаль районда гражданнар җыеннарын уздырганда көн тәртибенә уяулыкны саклау һәм террорчылык һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу мәсьәләләрен кертергә | ҖҮО башлыклары | 2026-2028 | авыл җирлекләрендә үткәрелгән җыеннар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |
| | | 2.8. Террорчылыкка каршы эчтәлектәге | БМР БК, «Татмеди | 2026-2028 | Урнаштырылган материаллар | 12 | 12 | 12 | 12 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны, социаль челтәрләрнең муниципаль сегментында, район Интернет челтәренең башка мәгълүмат ресурсларында эшләүне (сайлап алуны) һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | а» ААҖ филиал ы | | саны | | | | | | | | |
| | | 2.9. Рәсми дини конфессияләр (православие, ислам) вәкилләренең терорчылыкка каршы эшендә ватандашларны берләштерүгә юнәлтелгән тематик вәгазьләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны оештырырга | БМР БК, «Татмедиа» ААҖ филиалы, дини һәм иҗтимагый оешмалар (килешү буенча) | 2026-2028 | Басылган материаллар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2.10. Террорчылыкка каршы юнәлдерелгән документаль һәм нәфис фильмнар авыл клубларында һәм мәдәният йортларында даими рәвештә күрсәтүләрне оештырырга, аннары аудитория белән фикер алышырга | БМР БК МәдБ | 2026-2028 | Күрсәтүләр саны | 10 | 10 | 10 | 10 | * | * | * | * |
| | | 2.11. Яшьләр арасында кейс чемпионатлар, квестлар, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, фестивальләр, конкурслар, акцияләр оештырырга | БМР БК ЯЭСБ | 2026-2028 | Чаралар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2.12. Терроризмга һәм экстремизмга каршы көрәш өлкәсендә иң яхшы проектка (иҗат эшенә) конкурс үткәрергә | БМР БК ЯЭСБ | 2026-2028 | Конкурска заявкалар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | * | * | * | * |
| | | 2.13. Коммуникатив күнекмәләрне арттыруга, татулык, милләтара һәм динара татулык идеяләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән тематик түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, конкурслар, ата-аналар җыелышлары, сыйныф сәгатьләре, акцияләр, тренинглар оештыру | БМР БК МБ | 2026-2028 | Чаралар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | * | * | * | * |
| | | 2.14. Үзара аңлашу, милләтара теләктәшлек, | БМР БК МБ | 2026-2028 | Гаиләләрнең гомуми санында профилактик | 65 | 70 | 75 | 80 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | балаларның медиаиминлеге мәсьәләләрендә белем дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән «Ата-аналар өчен университет» форматы кысаларында дәресләр үткәрүне оештырырга | | | дәресләр белән колачланган ата-аналар өлеше, % | | | | | | | |
| | | 2.15.Террорчылык идеология сенә каршы тору чараларын үткәрүдә катнашкан белгечләр өчен семинар-укыту уздырырга | Мәдәният бүлеге | 2026-2028 | | | | | | - | 50,0** | 50,0** | 50,0** |
| | | 2.16.Сәламәтләндерү лагерьлары базасында экстремизм һәм террорчылык идеологиясен кабул итмәүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-пропаганда | Яшьләр бүлеге | 2026-2028 | | | | | | - | 100,0** | 100,0** | 100,0** |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чараларын үткәрергә | | | | | | | | | | | |

Искәрмәләр:

* Финанслау күләмнәре программага кертелгән предприятиеләрне һәм учреждениеләрне агымдагы финанслау исәбенә каралган.

** Финанслау күләмнәре өстәмә керемнәр булганда каралган.

**Файдаланылган кыскартулар исемлеге:**

| Кыскартылган исеме | Тулы исеме |
|---|---|
| Башкарма комитет | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| ТКК | Биектау районы Терроризмга каршы комиссиясе |
| ММЧ | Массакүләм мәгълүмат чаралары |
| АҖ | Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре |
| ПКО | Потенциаль куркыныч объектлар |
| БМР БК МБ | «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МУ |
| БМР БК МәдБ | «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәдәният бүлеге» МУ |
| БМР БК ЯЭСБ | «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт бүлеге» МУ |
| БУ | Район белем бирү учреждениеләре |
| ДОУ | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре |
| «Форпост» Үзәге МБУ | «Форпост» иҗтимагый тәртип саклау яшьләр үзәге муниципаль бюджет учреждениесе |
| ҖБ | Җирле бюджет |
| Районда «Татмедиа» филиалы | «Татмедиа» ААҖ Филиалы «Биектау хәбәрләре» газетасы редакциясе |